Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авылы җирлегенең Чулпан авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авылы җирлеге составына керүче Чулпан авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

# КАРАР

2019 елның 18 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 18 ноябрендә Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлегенең Чулпан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән, I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаларны куллану хакында гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Чулпан авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм вак таш салу) ;

- урам утларын карап тоту (Чулпан авылында урамнарны яктырту яктырткычларын энергия саклаучы светодиод яктырткычларга алыштыру);

- Чулпан авылында су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләрен төзү һәм ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 84 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 43 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 43 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авылы җирлегенең Чулпан авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган һәм гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авылы җирлегенең Чулпан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән һәм I төркем инвалидларыннан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча:

- Чулпан авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм вак таш салу) ;

- урам утларын карап тоту (Чулпан авылында урамнарны яктырту яктырткычларын энергия саклаучы светодиод яктырткычларга алыштыру);

- Чулпан авылында су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләрен төзү һәм ремонтлау буенча кабул ителде дип танырга.

3. Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Чулпан авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авылы җирлегенең Чулпан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән, I төркем инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Чулпан авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм вак таш салу) ;
- урам утларын карап тоту (Чулпан авылында урамнарны яктырту яктырткычларын энергия саклаучы светодиод яктырткычларга алыштыру).
- Чулпан авылында су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләрен төзү һәм ремонтлау.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Баганалысы
авыл җирлеге башлыгы _________________ Р.Р.Җәббаров